ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 май 2022 ел № 2725

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5598 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5598 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 25 февралендәге 847 номерлы, 2021 елның 12 мартындагы 1712 номерлы, 2021 елның 15 апрелендәге 2599 номерлы, 2022 елның 31 мартындагы 1698 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын тормышка ашыруга чараларны финанслауны шәһәр бюджетында «Балаларга өстәмә белем бирү» 0703, «Мәдәният» 0801 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 1137524,99 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2020 елда – 336945,45 мең сум; 2021 елда – 397771,05 мең сум; 2022 елда – 402 808,49 мең сум.»;

2) 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел (мең сум) | 2021 ел (мең сум) | 2022 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 336 945,45 | 395 271,05 | 402 808,49 | 1 135 024,99 |
| | Федераль бюджет | - | 2 500,0 | - | 2 500,0 |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 336 945,45 | 397 771,05 | 402 808,49 | 1 137 524,99»; |

- 4 бүлектә:

- «2020-2022 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасында «Ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанслау структурасы

мең сум

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслау күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 226 790,57 | 72 928,89 | 75 183,38 | 78 678,3 |
| Барлыгы | 226 790,57 | 72 928,89 | 75 183,38 | 78 678,3»; |

- 4 пунктта «2022» баганасында «78678,3» цифрларын «77628,32» цифрларына алмаштырырга;

- «2020-2022 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасында «Ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

«Финанслау структурасы

мең сум

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслау күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 77 217,18 | 22 702,64 | 29 283,19 | 25 231,35 |
| Барлыгы | 77 217,18 | 22 702,64 | 29 283,19 | 25 231,35»; |

- 4 пунктта «2022» баганасында «24991,3» цифрларын «25181,35» цифрларына алмаштырырга;

- «2020-2022 елларга муниципаль концерт учреждениеләрен үстерү» ярдәмче программасында «Ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанслау структурасы

мең сум

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслау күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча бүлеп | | |
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 144 754,52 | 39 613,58 | 55 846,63 | 49 294,31 |
| Барлыгы | 144 754,52 | 39 613,58 | 55 846,63 | 49 294,31»; |

- 3 пунктта «2022» баганасында «46976,1» цифрларын «49294,31» цифрларына алмаштырырга;

- «2020-2022 елларга мәдәни-ял учреждениеләрен үстерү» ярдәмче программасында «Ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанслау структурасы мең сум

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслау күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча бүлеп | | |
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 415 487,77 | 117 305,49 | 146 947,83 | 151 234,45 |
| Барлыгы | 415 487,77 | 117 305,49 | 146 947,83 | 151 234,45»; |

- 3 пунктта «2022» баганасында «148880,4» цифрларын «151234,45» цифрларына алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов